**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге**

---

**КАРАР** **КАРАР**

**25.11.2025 ел** **№6**

2020 елның 27 февралендәге 145 номерлы
«Җир салымы турында» карарга
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрндәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Иске Имән авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 27 февралендәге 145 номерлы карарына (Советның 2020 елның 12 ноябрендәге, 11 номерлы, 2023 елның 22 февралендәге 73 номерлы, 2023 елның 2 ноябрендәге 84 номерлы, 2025 елның 7 февралендәге 125 номерлы, 2025 елның 20 октябрендәге 5 номерлы карарларында кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.2.2 пунктчасы өстәргә:

4.2.2. күпфатирлы йортлар астында урнашкан җир кишәрлекләре өчен торак милекчеләре ширкәтләренә;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернетны мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Ә.Исламова